КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«18» ноябрь 2019 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2019 елның 11нче, 14 нче һәм 18 ноябрендә узган: «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Бикүле торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау (грунттан юл өслеген күтәрү, вак таш сатып алу, ташу, салу, транспорт хезмәтләре);

2) Бикүле авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү;

3) Бикүле авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру” мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 439 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 269 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 261 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 8 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Бикүле торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау (грунттан юл өслеген күтәрү, вак таш сатып алу, ташу, салу, транспорт хезмәтләре);

2) Бикүле авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү;

3) Бикүле авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру” мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыены рәисе: Р.Х.Садыйков

Бикүле авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Садыйков